ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы һәлакәттән коткару хезмәтләре һәм һәлакәттән коткару формированиеләре турында» Татарстан Республикасы Законының 9 һәм 11 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 574-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы һәлакәттән коткару хезмәтләре һәм һәлакәттән коткару формированиеләре турында» Татарстан Республикасы Законының 9 һәм 11 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 574-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2024 елның 11 июле
№ 2588-VI ДС

проект

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинеты
тарафыннан кетрелә

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ЗАКОНЫ

## «Татарстан Республикасы һәлакәттән коткару хезмәтләре һәм һәлакәттән коткару формированиеләре турында» Татарстан Республикасы Законының 9 һәм 11 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

**1 статья**

«Татарстан Республикасы һәлакәттән коткару хезмәтләре һәм һәлакәттән коткару формированиеләре турында» 2005 елның 29 декабрендәге 134-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 12 (IV өлеш); 2008, № 10 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш); 2012, № 3; 2013, № 5; 2014, № 5, № 6 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнары җыентыгы, 2017, № 76 (I өлеш); 2021, № 77 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 9 статьяның 2 өлешендә «формированиеләрен теркәүне» сүзләреннән соң «халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдә яклау өлкәсендәге бурычларны хәл итү буенча махсус вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы,» сүзләрен өстәргә;

2) 11 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11 статья. **Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан төзелгән Татарстан Республикасы һәлакәттән коткару хезмәтләрен һәм һәлакәттән коткару формированиеләрен һәлакәттән коткару чаралары белән тәэмин итү**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан төзелгән Татарстан Республикасы һәлакәттән коткару хезмәтләрен һәм һәлакәттән коткару формированиеләрен һәлакәттән коткару эшләренең игълан ителгән төрләрен үтәүне тәэмин итүче һәлакәттән коткару чаралары белән тәэмин итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан расланган тәэмин итү нормалары нигезендә гамәлгә ашырыла.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасы һәлакәттән коткару хезмәтләре һәм һәлакәттән коткару формированиеләре турында» Татарстан Республикасы Законының 9 һәм 11 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы закон проектына**

**АҢЛАТМА**

Закон проекты һәлакәттән коткару хезмәтләре һәм һәлакәттән коткару формированиеләре эшчәнлеген оештыру өлкәсендә Татарстан Республикасы норматив хокукый базасын алга таба үстерү максатларында эшләнде.

Закон проекты белән 1995 елның 22 августындагы «Һәлакәттән коткару хезмәтләре һәм коткаручылар статусы турында» 151-ФЗ номерлы Федераль закон һәм Россия гадәттән тыш хәлләр министрлыгының 2018 елның 12 мартындагы «Һәлакәттән коткару хезмәтләрен һәм һәлакәттән коткару формированиеләрен теркәү тәртибен раслау турында» 99 номерлы боерыгы нигезендә һәлакәттән коткару хезмәтләрен һәм һәлакәттән коткару формированиеләрен теркәүне гамәлгә ашыручы органнарны ачыклау тәкъдим ителә. Күрсәтелгән максатларда «Татарстан Республикасы һәлакәттән коткару хезмәтләре һәм һәлакәттән коткару формированиеләре турында» 2005 елның 29 декабрендәге 134-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының (алга таба – 134-ТРЗ номерлы Закон) 9 статьясындагы 2 өлешенә тиешле үзгәрешләр кертелә.

Шулай ук закон проекты белән федераль законнарга ярашлы рәвештә һәлакәттән коткару хезмәтләрен һәм һәлакәттән коткару формированиеләрен матди-техник тәэмин итү мәсьәләләрен аныклау тәкъдим ителә.

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2011 елның 22 декабрендәге «Һәлакәттән коткару хезмәтләрен һәм һәлакәттән коткару формированиеләрен, коткаручыларны һәм коткаручы статусын алган гражданнарны аттестацияләүнең кайбер мәсьәләләре турында» 1091 номерлы карарына ярашлы рәвештә һәлакәттән коткару хезмәтен (формированиене) аттестацияләгәндә куелган мәҗбүри таләпләр дип, шул исәптән, һәлакәттән коткару хезмәтен (формированиене) гамәлгә куючылар тарафыннан расланган тәэмин итү нормаларына ярашлы рәвештә һәлакәттән коткару эшләренең игълан ителгән төрләрен башкаруны тәэмин итүче һәм әлеге хезмәткә (әлеге формированиега) милек хокукында яки башка законлы нигездә аттестациянең гамәлдә булу вакытыннан да ким булмаган срокка бирелгән һәлакәттән коткару чаралары белән тәэмин ителеш тора дип билгеләнгән.

Күрсәтелгән нормага туры килүне тәэмин итү максатыннан 134-ТРЗ номерлы законның 11 статьясында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан оештырылган һәлакәттән коткару хезмәтләрен һәм һәлакәттән коткару формированиеләрен һәлакәттән коткару эшләренең игълан ителгән төрләрен башкаруны тәэмин итүче һәлакәттән коткару чаралары белән тәэмин итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана торган тәэмин итү нормалары нигезендә гамәлгә ашырыла дип билгеләү тәкъдим ителә.

Закон проектын кабул итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан оештырылган һәлакәттән коткару хезмәтләренең һәм һәлакәттән коткару формированиеләренең тәэмин ителеш нормаларын раслаучы документларны әзерләү мәсьәләләрен хәл итүдә хокукый ачыкланмаган урыннарны булдырмаска мөмкинлек бирәчәк.

**«Татарстан Республикасы һәлакәттән коткару хезмәтләре һәм һәлакәттән коткару формированиеләре турында» Татарстан Республикасы Законының 9 һәм 11 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасы һәлакәттән коткару хезмәтләре һәм һәлакәттән коткару формированиеләре турында» Татарстан Республикасы Законының 9 һәм 11 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яки кабул итүне таләп итми.

Законны кабул итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы һәлакәттән коткару профессиональ хезмәтләрен һәм һәлакәттән коткару профессиональ формированиеләрен җиһазландыру табелен раслау турында» 2013 елның 23 декабрендәге 1029 номерлы карарына үзгәрешләр кертүне таләп итә.

**«Татарстан Республикасы һәлакәттән коткару хезмәтләре һәм һәлакәттән коткару формированиеләре турында» Татарстан Республикасы Законының 9 һәм 11 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы закон проектын**

# ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ

«Татарстан Республикасы һәлакәттән коткару хезмәтләре һәм һәлакәттән коткару формированиеләре турында» Татарстан Республикасы Законының 9 һәм 11 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә акчалар бүлеп бирүне таләп итмәячәк.